28 мартта Республика мәдәният сараенда Мәдәният хезмәткәрләре коненә багышланган тантаналы чара узды.
Артистларны, рәссамнарны, музыкантларны, ижат коллективлары житәкчеләрен - залдагы барлык кунак-ларны Мордовия Республикасы Главасы Артём Алексеевич Здунов котлады.
- Бvген без хормәт белән аерым миссия бирелгән, талант бирелгән кешеләрне хормәтлибез. Сез кешеләрдә омет уятасыз, аларга эшләргә, киләчәккә оптимизм белән карарга ярдәм итәсез.

Мәдәниятсез – берничек тә була алмый: бар нәрсә жырлар, унай хис-кичерешләр белән башкарыла. Һәрвакыт шулай булды: Боек Ватан сугышы елларында да, хәзер дә. Сезгә бетмәс-токәнмәс энергия телим, онытмагыз, бу энергияне сез кешеләргә тапшырасыз! - диде республика житәкчесе.
Бу конне Дәvләт бvләкләре тапшырылды. Мәдәният олкәсендәге казанышлары һәм кvпьеллык намуслы хезмәте очен «Мордовия Республикасынын атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем Ләмберә районы «Алмаз» мәдәни-спорт vзәгенен «Кривозерье авыл клубы» муниципаль автоном учреждениесенен 7нче филиалы модире, «Хыял» милли ансамбле житәкчесе Наилә Шәйхатдяр кызы Манеевага бирелде.
Атказанган Наилә Шәйхатдяр кызы Манеева, алда зур унышлар котсен сезне, исән-сау булыгыз!